**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
**06.08.2024 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№37-08**

**Актаныш муниципаль районы җирлекләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Актаныш, Актанышбаш, Аеш, Аккүз, Әтәс, Югары Яхшый, Кәзкәй, Киров, Күҗәкә, Мәсәде, Яңа Әлем, Пучы, Иске Айман, Иске Байсар, Иске Богады, Иске Сәфәр, Иске Кормаш, Такталачык, Татар Ямалысы, Татар Суыксуы, Теләкәй, Түке, Уразай, Усы, Чалманарат, Чуракай авыл җирлекләренең вәкиллекле органнарының, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге җирлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлек тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү.

2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына:

Актаныш муниципаль районы җирлекләренең башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне кушымтага ярашлы рәвештә, типовой форма нигезендә тапшыру турында килешүләр төзергә.;

Әлеге карарның тормышка ашырылуын тәэмин итү максатларында, Актаныш муниципаль район Советының 2024 елга һәм 2025-2026 еллар план чорына бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләү һәм бюджет законнары нигезендә карауга тапшыру.

3. Актаныш муниципаль районының җирле үзидарә органнары әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән килешүне гамәлгә ашыру өчен үз компетенцияләре чикләрендә норматив һәм норматив булмаган хокукый актлар чыгарырга хокуклы дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны рәсми рәвештә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль район Советы Законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге буенча даими комиссиянә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Л.Р.Зарипов

Актаныш муниципаль районы
Советы карарына
06.08.2024 ел, №37-08 кушымта

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча __________ Башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында килешү

(типик формасы)

__________ ________202__ел

Бер яктан _________ Уставы (җирлек атамасы) нигезендә эш итүче Башкарма комитет җитәкчесе ____________ (җирлек башкарма комитеты җитәкчесенең ФИО), һәм Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты исеменнән, алга таба “Район Башкарма комитеты” дип аталачак, Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә эш итүче башкарма комитет җитәкчесе Ильясов Рөстәм Алмаз улы, икенче яктан, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә таянып, “Яклар” түбәндәгеләр турында әлеге килешүне төзеделәр:

1. Килешү предметы

1.1. Әлеге Килешү җирлек башкарма комитетының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлешен район Башкарма комитетына тапшыруны беркетә.

1.2. Җирлекнең башкарма комитеты район Башкарма комитетына түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тапшыра:[1]

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлек тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү.

1.3. Яклар әлеге Килешүне гамәлгә ашыру кысаларында мәгълүмат алмашырга йөкләмә ала.

2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Районның Башкарма комитеты әлеге Килешүнең 1 бүлеге нигезендә җирлекнең башкарма комитеты тапшырган вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2.2. Районның Башкарма комитеты Нигезләмә нигезендә әлеге Килешү нигезендә тапшырылган вәкаләтләрнең бер өлешен башкарачак вазыйфаи затны яисә структур бүлекчәне билгели.

2.3. Районның Башкарма комитеты, җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеген күрсәтү кысаларында эшләр башкару өчен, физик яисә юридик затлар белән контракт (килешү) төзи.

2.4. Әлеге Килешү буенча тапшырылган вәкаләтләр кысаларында эшчәнлекне гамәлгә ашыру өлешендә район Башкарма комитеты җирлекнең башкарма комитетына хисап тота.

[1] Исемлек киңәйтелергә мөмкин.

3. Бюджетара трансфертларның еллык күләмен билгеләү тәртибе

3.1. Әлеге Килешү предметы буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру ел саен җирлек бюджетыннан муниципаль район бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3.2. Яклар ел саен тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләмен бюджет турында ел саен раслана торган карарлар нигезендә билгели (әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган кушымталар нигезендә).

3.3. Әлеге Килешүнең 1.2 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга җирлек бюджетыннан муниципаль район бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертларны формалаштыру, күчерү һәм исәпкә алу Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Килешүнең гамәлдә булу вакыты, аны туктату вакыты һәм тәртибе

4.1. Әлеге Килешү рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4.2 Әлеге Килешү "___"___________ 202_ елга кадәр гамәлдә.

4.3. Әлеге килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

яклар килешүе буенча;

якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән, яки гамәлдәге законнар килешүнең алга таба гамәлдә булмавына китерә торган үзгәргән очракта берьяклы тәртиптә.

4.4. Әлеге Килешүне өзү турындагы хәбәрнамә, эш тәмамлану фаразланган датага кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча, язма рәвештә икенче якка җибәрелә.

4.5. Әлеге килешү буенча тапшырыла торган кайбер вәкаләтләрне туктату башка вәкаләтләрне туктатуга китерми.

4.6. Әгәр дә әлеге Килешүнең 4.2 пунктында күрсәтелгән вакыт узганнан соң яклар Килешүне өзү ниятен утыз көн дәвамында белдермәсә, ул киләсе календарь ел тәмамланганчы озайтылган дип санала.

5. Якларның җаваплылыгы

5.1. Яклар әлеге Килешүдә гамәлдәге законнар нигезендә каралган бурычларны тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

5.2. Районның Башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган вәкаләтләрне тиешенчә гамәлгә ашырмау фактын билгеләү әлеге Килешүне берьяклы өзү өчен нигез булып тора. Килешүне өзү санап үтелгән бюджетара трансфертларны кире кайтаруга, документлар белән расланган факттагы чыгымнарны Килешүне өзү яисә өзү турында язма хәбәрнамә алган вакыттан соң 30 көн эчендә кире кайтаруга, шулай ук күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга җирлек бюджетыннан бүлеп бирелгән хисап елында бюджетара трансфертлар суммасының 0,01% күләмендә неустойка түләүгә китерә.

5.3. Районның Башкарма комитеты үзенә тапшырылган вәкаләтләрне башкару өчен әлеге вәкаләтләр финанс чаралары белән тәэмин ителгән дәрәҗәдә җаваплы була.

5.4. Җирлек башкарма комитеты аңа тапшырылган вәкаләтләрне башкаруны финанслау буенча әлеге килешүдән килеп чыга торган йөкләмәләрне үтәмәгән очракта, район Башкарма комитеты әлеге Килешүне өзүне, шулай ук китерелгән зыянны каплауны таләп итәргә хокуклы.

6. Башка мәсьәләләр

6.1. Якларның үзара ризалыгы яисә гамәлдәге законнар таләпләре нигезендә әлеге Килешүгә язма рәвештә әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган үзгәрешләр һәм (яисә) өстәмәләр кертелергә мөмкин.

6.2. Әлеге Килешүне үтәгәндә барлыкка килгән яклар тарафыннан җайга салынмаган бәхәсләр һәм каршылыклар гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә каралырга тиеш.

6.3 Әлеге Килешү тигез юридик көчкә ия һәм 2 (ике) нөсхәдә, һәр як өчен берәр нөсхәдә төзелә.

| | |
|---|---|
| ______________Башкарма комитеты<br>(җирлекнең атамасы)<br>Адресы: _________________________<br>_______________Башкарма комитет җитәкчесе (җирлек атамасы)<br>________________________________<br>(ФИО)<br>_________________<br>(имза) | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты<br>Адресы: 423740, ТР, Актаныш муниципаль районы, Актаныш ав., Ленин пр., 17 й.<br>Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;<br>_____________________ Р.А.Ильясов<br>(ФИО)<br>(имза) |